СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.07.2026 пгт Аксубаево №48

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында Муниципаль торак контроле турында нигезләмә»турындагы 23.09.2021 N 72 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставын күздә тотып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау турында" Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 23.09.2021 N 72 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертелсен:

1.1. 1.2 пунктның беренче абзацында «милек рәвешенә бәйсез рәвештә»сүзләрен өстәргә.,;

1.2. 1.2 пунктның 9 пунктчасы түбәндәге редакциядә жазылсын:

9) торак-коммуналь хуҗалык системасында ресурсларны тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, төбәк операторлары, төзүчеләр, күпфатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итүче күпфатирлы йортта бүлмә милекчеләре белән хезмәт күрсәтү шартнамәләре төзелгән һәм (яки) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне ремонтлау буенча эшләрне күпфатирлы йортта мондый йорт хуҗалары тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан башкару;".

2. Бу карар Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http ://Aksubaevo.tatarstan/ru урнаштырылсын һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырылсын: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Бу Карарның үтәлешен контрольдә тоту Аксубай муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар, җыемнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләнсен

Муниципаль районы башлыгы,
Рәис Советы

А.М.Миңгулов